**КАРАР**

**“11” ноябрь 2020 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 11 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:
«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм Сәгъдуллин ур., 50 адресы буенча урнаштыру;
- Төньяк урамының 35нче йортыннан 30 нчы йортына кадәр, Сәгъдуллин урамының 34 нче йортыннан 50 нче йортына кадәр, Тукай урамының 5 нче йортыннан 2а йортына кадәр, Яшьләр урамынын 1нче йортыннан 6 нчы йортына кадәр, Тынычлык урамының 7 нче йортыннан 9 нчы йортына кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю;
- Бакча урамы, 9А йорт адресы буенча су башнясын киртәләп алу һәм территориясен төзекләндерү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 712 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 374 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 363 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 11 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге

Шушмабаш авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм Сәгъдуллин ур., 50 адресы буенча урнаштыру;

- Төньяк урамының 35нче йортыннан 30 нчы йортына кадәр, Сәгъдуллин урамының 34 нче йортыннан 50 нче йортына кадәр, Тукай урамының 5 нче йортыннан 2а йортына кадәр, Яшьләр урамынын 1нче йортыннан 6 нчы йортына кадәр, Тынычлык урамының 7 нче йортыннан 9 нчы йортына кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю;

- Бакча урамы, 9А йорт адресы буенча су башнясын киртәләп алу һәм территориясен төзекләндерү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б йорт, Мәктәп урамы, 8 йорт, Мәктәп урамы, 5 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов